**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Туйкә авыл җирлеге Советы карары**

Туйкә авылы № 170-77 «24» 04 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының 2016 елның 18 июне 36-15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында ( 31.10.2016 № 43-21, 25.09.2017 № 69-33, 16.02.2018 №87-41, 30.12.2019 №158-73 карарлар редакциясендә)

2009 елның 2 августындагы 301-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Туйкә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының 2016 елның 18 июненән 36-15 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә ( 31.10.2016 № 43-21, 25.09.2017 № 69-33, 16.02.2018 № 87-41, 30.12.2019 №158-73 карарлар редакциясендә) түбәнәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 бүлекнең 3 пунктында "федераль закон белән билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләменнән илле мең тапкыр артып китә" сүзләрен "федераль закон белән билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләменнән 10 тапкыр артып китә" сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 11 бүлекнең 3 абзацында "федераль закон белән билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләме илле мең тапкырдан артып китә" сүзләрен "Ачык җәмгыять устав капиталының федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән 50 тапкырдан артык"сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб -адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы муниципаль

бөрәмлекләре порталы составында Азнакай муниципаль районының мәгълүмат сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р.Р.Закирова